527. Түбәндәге язмаларның кайсысы әхлак нормасы мисалларына туры килә?

1) Тешләрне көненә ике тапкыр чистартырга кирәк.
2) Транспортта билетсыз йөргәнгә штраф белән җәза бирелә.
3) Фатирга беренче булып мәче керергә тиеш.
4) Дусны авыр тормыш вәзгыятендә ташлап калдырырга ярамый.

528. Социаль норма төрләре һәм мисаллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килә торган элементны сайлап алыгыз.

| МИСАЛЛАР | СОЦИАЛЬ НОРМА ТӨРЛӘРЕ |
|---|---|
| А) Югары сыйныф укучылары беренче | 1) әхлак нормалары |
| сыйныф укучысына югалган әйберләрен табарга | 2) традицияләр |
| булыштылар. | |
| Б) Һәр ел саен мәктәптә театр фестивале уза. | |
| В) Балигъ булмаган К., әти-әниләренә сеңелен сәламәтләндерүгә акча белән ярдәм итү максатыннан, каникуллар вакытында эшкә урнаша. | |
| Г) Ял көннәрендә бар гаилә көндезге ашка җыела. | |
| Д) Дәресләрдән соң мәктәп укучылары өлкән яшьтәге кешеләргә хуҗалык эшләрендә булышалар. | |

Сайлап алынган цифрларны тиешле хәрефләр астына таблицада язып куегыз.

529. Гаиләне башка социаль төркемнәрдән нәрсә аерып тора?

1) мәнфәгатьләрнең берлеге
2) эшчәнлекнең уртак максатлары
3) үз-узеңне тоту кагыйдәләре
4) уртак көндәлек тормыш алып бару

530.Социаль рольләр турындагы фикерләр дөресме?

А. Ата-аналарның бала тәрбияләүдә катнашулары социаль норма булып тора.

Б. Социаль нормалар, кагыйдә буларак, җәмгыятьнең икътисадый элитасы тарафыннан барлыкка киләләр.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

531. Кешенең социаль хәленә туры килеп көтелгән тәртибе ничек атала?

1) социаль статус

2) социаль роль

3) абруй (авторитет)

4) иҗтимагый абруй

532. “Яхшылык эшләргә ашыгыгыз” дигән принцип булуы мәгълүм. Ул ... керә.

1) хокук нормалары

2) сәяси нормалар

3) эстетик нормалар

4) әхлак нормалар

533. Җәмгыятьнең социаль структурасы турындагы фикерләр дөресме?

А. Җәмгыятьнең социаль структурасы төрле профессиональ төркемнәрне үз эченә ала.

Б. Җәмгыятьнең социаль структурасы аның тарихи тибына бәйле.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

534. Гаилә, мәктәп сыйныфы нинди төркем булып тора?

1) этник бердәмлек

2) кече төркемнәр

3) социаль катламнар

4) формаль булмаган төркемнәр

535. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?

А. Ата-аналарның бала тәрбияләүдә катнашулары социаль норма булып тора.

Б. Социаль нормалар, кагыйдә буларак, җәмгыятьнең икътисадый элитасы белән билгеләнә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

536. Түбәндә бирелгән социаль рольләр турындагы фикерләр дөресме?

А. Социаль роль индивид тарафыннан социальләшү процессы вакытында үзләштерелә.

Б. Кешенең барлык социаль рольләре дә, һичшиксез, стандартлашкан булырга тиеш.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

537. Аннага 17 яшь, ул урта мәктәпне тәмамлый. Аның гаиләсе – әти-әнисе һәм ике апасы. Түбәндәге сыйфатламаларда нәрсә чагыла?

1) шәхеснең социаль роле
2) шәхси абруй
3) шәхеснең социаль статусы
4) кешенең билгеле бер этник төркемгә каравы

538. Санап кителгәннәрнең кайсысы җәмгыятьнең социаль төзелешен билгеләү өчен иң мәгънәви билге булып тора?

1) Кешеләрнең танып белү мәнфәгате

2) Кешеләрнең характер зенчәлеге

3) Кешеләрнең акыл сәләте

4) Кешеләрнең белем дәрәҗәсе

539. Нинди социаль роль яшүсмерләргә дә, өлкән яшьтәгеләргә дә хас?

1) опекун

2) сайлаучы

3) кулланучы

4) мәктәп укучысы

540. Гаиләне башка социаль төркемнәрдән нәрсә аерып тора?

1) мәнфәгатьләрнең берлеге

2) эшчәнлекнең уртак максатлары

3) эшчәнлекнең кагыйдәләре булу

4) уртак тормыш алып бару

541. Яшүсмер нинди социаль роль үти ала?

1) Контракт нигезендә хезмәт итүче хәрби

2) Кече энесенә опекун

3) Автобус йөртүче

4) Интернет-сайт кулланучысы

542. Җәмгыятьнең төзелеше социаль төркемнәрнең һәм гомумилекләрнең төрле характердагы бәйләнешләре нигезендә барлыкка килә. Кайсы социаль төркем территориаль билге буенча аерыла?

1) хатын-кызлар

2) яшүсмерләр

3) программистлар

4) петербурглылар

543. Пётр әти-әнисе һәм әбисе белән яши. Ул 8 нче сыйныфта укый. Кече төркем буларак, гаиләгә дә, мәктәп сыйныфына да нинди билге хас?

1) Көндәлек тормыш алып бару берлеге

2) Уртак хуҗалык алып бару

3) Туганлык җепләре

4) Турыдан-туры шәхси бәйләнешләр

544. Гаиләләр ... белән характерлана.

1) Йорт вазифаларын хатын-кызга йөкләү

2) Хатын-кызның икътисадый яктан ир-атка бәйле булу

3) Йорт вазифаларын гадел бүлү

4) Йорт хуҗалыгы булу, уртак тормыш итү

545. “Традицияләр”, “йола” терминнары, беренче чиратта, түбәндәге төшенчәләрне ачар өчен кулланыла.

1) Социаль төзелеш

2) Социаль роль

3) Социаль тигезсезлек

4) Социаль нормалар

546. Түбәндәге социаль конфликт турындагы фикер йөртүләр дөресме?

А. Социаль конфликт һәрвакыт негатив нәтиҗәләргә генә китерә.

Б. Социаль конфликтлар формалары һәм үсү-үзгәрү характерлары буенча аерылалар.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

547. Социаль рольләр турындагы түбәндәге фикерләрнең кайсы дөрес?

А. Яшүсмер эшли ала торган социаль рольләрнең берсе – кибеттә сатып алучы.

Б. Яшүсмерләр зурларга хас булган барлык социаль рольләрне дә башкара алмыйлар.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

548. Түбәндә китерелгән кешеләрнең уз-үзләрен тоту вәзгыятьләреннән (ситуацияләрдән) кайсысы, иң беренче чиратта, әхлак нормалар белән җайга салына?

1) Фатирларның берсендә шау-шулы төзелеш эшләренә чик кую максаты белән, күршеләр полиция бүлегенә мөрәҗәгать иттеләр.

2) Сатучы акрын эшли, шунлыктан аның бүлегенә сатып алучылардан чират җыелды.

3) Ханым үзенең улына аталыкны билгеләү максатыннан, судка дәгъва белән мөрәҗәгать итте.

Укытучы укучыны өлкән яшьтәге ханымга юлны аркылы чыгарга булышуы өчен мактады.

549. Җәмгыятьнең социаль структурасы турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Җәмгыятьнең социаль структурасы – ул төрле типтагы социаль бердәмлекләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр.

Б. Социаль структура социаль тигезсезлекне чагылдыра.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

550. Җәмгыятьнең социаль структурасы турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Җәмгыятьнең социаль структурасы катламнарны, классларны, этносларны үз эченә ала.

Б. Җәмгыятьнең социаль структурасы җәмгыятьнең икътисадый үсешенә бәйле рәвештә үзгәрә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

551. Милләтара мөнәсәбәтләр турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Заманча халыклар, кагыйдә буларак, иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә хезмәттәшлекне киңәйтергә омтылалар.

Б. Милләтара мөнәсәбәтләр бары дәүләт дәрәҗәсендә генә гамәлгә ашырыла.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

552. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?

А.  Социаль нормаларның үтәлеше  бары тик җәмәгатьчелек фикере белән генә тәэмин ителә.

Б.  Социаль нормалар җәмгыять тормышын җайга салалар.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

553. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А.  Иҗтимагый тормышта  катнашучыларның  мәнфәгатьләре туры килмәү социаль конфликтның сәбәбе булып тора.

Б.  Социаль конфликтлар бары тик тискәре нәтиҗәләргә генә китерә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

554. Гаилә турындагы  фикерләр дөресме?

А. Теркәлгән никахта торып, бергә яшәүче һәм уртак хуҗалык алып баручы ир-ат һәм хатын-кыз берлеге гаилә дип атала.

Б. Гаилә әгъзалары уртак гомуми көнкүреш, әхлак һәм хокукый җаваплылык белән бәйләнгән

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

555.  Җәмгыятьнең төзелеше социаль төркемнәрнең һәм гомумилекләрнең төрле характердагы бәйләнешләре нигезендә барлыкка килә. Кайсы социаль төркем  территориаль билге буенча аерыла?

1)  хатын-кызлар

2)   яшүсмерләр

3)   либераллар

4) Ростов шәһәрендә яшәүчеләр

556. “Традицияләр”, “йола” терминнары, беренче чиратта, түбәндәге төшенчәләрне ачар өчен кулланыла.

1) җәмгыять
2) дөньяви дәүләт
3) сәяси режим
4) социаль нормалар

557. С. гаиләсе ир белән хатынны һәм аларның балигъ булмаган ике баласын үз эченә ала. Бу гаиләне кайсы төргә кертеп була?

1) нуклеар гаилә
2) киңәйтелгән гаилә
3) купбуынлы гаилә
4) тулы булмаган гаилә

558. Гаилә дә, хезмәт коллективы да нәрсә булып тора алалар?

1) территориаль бердәмлек
2) кече төркемнәр
3) социаль катламнар
4) формаль булмаган төркемнәр

559. Башка кече төркемнәрдә аермалы буларак, гаилә түбәндәге сыйфатлама белән характерлана

1) шәхси элемтәләр
2) партнерлык мөнәсәбәтләре булу
3) уртак кызыксынулар
4) уртак хуҗалык алып бару

560. Әти-әнисе улларын:” Әгәр дә күрешкәндә синнән “Ничек хәлләрең?” ,- дип сорасалар, бу әле алар турында тәфсилләп сөйләргә кирәк дигәнне аңлатмый”, - дип өйрәтәләр. Шул рәвешле эти-әни улларына нинди кагыйдәләр турында сөйлиләр.

1) фән
2) дин
3) әхлак
4) этикет

561. Шәхси оешма хуҗалары эшчеләрнең санын кыскартырга уйладылар. Эшчеләр забастовка игълан иттеләр. Бу факт нинди конфликтны чагылдыра?

1) сәяси
2) шәхесара
3) икътисадый
4) идеологик

562. Т. Парижда туа, аның әбисе Россиядән 1917 нче елгы революциягә (инкыйлаб) кадәр үк китә. Т. рус телен һәм рус мәдәниятен яхшы белә. Ул рус булуы белән горурлана. Бу нинди бердәмлекнең билгеләрен күрсәтә?

1) демографик

2) территориаль

3) этник

4) катлам

563. К. гаиләсендә кич белән җыелып, барлык проблемалар турында сөйләшү гадәте бар. Бу мисал кеше тормышында гаиләнең нинди ролен күрсәтеп тора?
1) Гаилә психологик ярдәм күрсәтә.
2) Олылар балаларның белем алу процессында катнашалар.
3) Гаилә сәламәт яшәү рәвешен хуплый.
4) Гаилә үзенең әгъзаларына икътисадый яктан ярдәм итә.

564. Яшүсмерләр, һәм шул ук вакытта олылар да, нинди социаль роль башкара алалар?

1) интернеттан файдаланучы
2) хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәткәр
3) сайлаучы
4) парламент депутаты

565. Иван Сергеевич – ашыгыч ярдәм табибы – көн саен эшкә метрода йөри. Пассажирларны берсе белән йөрәк өянәге булгач, Иван Сергеевич аңа беренче медицина ярдәме күрсәтә. Иван Сергеевич гамәлендә нәрсә чагыла?
1) социаль структура
2) социаль роль
3) социаль сәясәт
4) социаль конфликт

566. Бала гаиләдә башка кешеләр белән аралашу кагыйдәләрен үзләштерә. Бу вакытта гаилән роле нәрсәдә чагыла?
1) хуҗалык алып бару
2) шәхси вакытны оештыру
3) социаль статусны бирү
4) шәхеснең социализациясе

567. Андрей теләсә нинди тормыш вәзгыятендә (ситуациясендә) үзенең әти-әнисендә аңл ярдәм табуын белә. Бу мисал гаиләнең нинди ролен күрсәтеп тора?
1) Гаилә үзенең әгъзаларына психологик ярдәм күрсәтә.

2) Ата-ана балаларын рухи яктан баета.
3) Гаилә индивидның беренчел социальләшүенә ярдәм итә.
4) Ата-ана балаларын матди яктан тәэмин итәләр.

568. Кайсы социаль төркем профессиональ билге буенча бүлеп бирелгән?
1) пассажирлар
2) ир-атлар
3) инженерлар
4) шәһәр халкы

569. Әлеге зур этник төркемнәргә кешеләр уртак теле, мәдәнияте, территориясе, хуҗалык системасы нигезендә берләшәләр. Мондый төркемнәр нәрсә булып торалар?
1) класслар
2) милләтләр
3) сословияләр
4) халыкчанлык

570. Кайсы социаль төркем территориаль билге буенча аерыла?
1) регионда яшәүчеләр
2) тимер юл эшчеләре
3) яшүсмерләр
4) урам баскетболын яратучылар

571. “Яхшылык” һәм “явызлык”, “начар” һәм “яхшы” позициясеннән чыгып, кешеләрн тәртибен җайга салучы социаль нормаларны ничек дип атыйлар?
1) сәяси
2) хокукый
3) әхлак
4) эстетик

572. Кешеләрнең яхшы һәм начар гамәлләр турындагы күзаллауларын белдергән соци нормаларны ничек дип атыйлар?
1) сәяси
2) хокукый
3) әхлак
4) эстетик

573. Гаиләне башка кече төркемнәрдән нәрсә аерып тора?
1) уртак хезмәт эшчәнлеге
2) бердәм эстетик өстенлек бирү
3) сәяси карашлар гомумилеге
4) уртак хуҗалык алып бару

574. Кайсы социаль төркем территориаль билге буенча аерыла?
1) Новгородта яшәүчеләр
2) укытучылар

3) сатып алучылар

4) демократлар

575. Дөньяви дәүләттәге дини нормаларны күрсәтегез.

1) бар халыкка тарала

2) дәүләт көче белән тәэмин ителә

3) шәхес һәм хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала

4) дин тотучыларның әхлак аңы белән яклана

576. Гаилә ул -

1) зур социаль төркем
2) социаль институт
3) иҗтимагый тормыш өлкәсе
4) этник бердәмлек

577. Кайсы социаль роль яшүсмер тарафыннан да, шулай ук зурлар тарафыннан да башкарыл ала?

| | |
|---|---|
| 1) | суд приставы |
| 2) | автобус йөртүчесе |
| 3) | ир (хатын) |
| 4) | театр тамашачысы |

578. Кайсы социаль роль яшүсмер тарафыннан да, шулай ук зурлар тарафыннан да башкарыл ала?

**1)** сайлаучы

**2)** хәрби хезмәткә чакыру буенча хәрби хезмәткәр

**3)** театр тамашачысы

**4)** парламент депутаты

579. Түбәндә китерелгәннәрнең кайсысы традицияләргә мисал булып тора?

| | |
|---|---|
| **1)** | РФ Президенты үз вазифасына керешкәндә присяга кабул итә. |
| **2)** | Кәләш туйда ак күлмәк кия. |
| **3)** | Җитештерүче этикеткада продукт составын күрсәтергә бурычлы. |

| | |
|---|---|
| **4)** | Югары уку йортларына кабул ителү имтихан нәтиҗәләре нигезендә генә башкарыла. |

560. Социаль роль турындагы фикерләр дөресме?
А. Кешенең социаль статусыннан чыгып көтелгән үз-үзен тоту тәртибе социаль роль дип атала.
Б. Кешенең барлык социаль рольләре формаль кагыйдәләр белән җайга салына.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

561. Гаилә турындагы фикерләр дөресме?
А. Әгъзалары туганлык мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән кече төркем гаилә дип атала.
Б. Башка кече төркемнән аермалы буларак, гаилә әгъзалары арасында шәхси элемтәләр бар.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

562. Гаилә турындагы фикерләр дөресме?
А. Гаиләне башка кече төркемнәрдән әгъзаларының уртак көнкүрешләре булу аерып тора.
Б. Гаилә үзенең эшкә яраксыз әгъзаларына икътисадый ярдәм күрсәтеп тора.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

563. Социаль конфликт турындагы фикерләр дөресме?
А. Конфликтлы очраклар төрле типтагы җәмгыятьтә була.
Б. Крестьяннарның баш күтәрүе социаль конфликтның бер формасы булып тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

565. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?
А. Социаль нормалар иҗтимагый үсеш вакытында барлыкка киләләр.
Б. Социаль нормалар индивид һәм төркемнәрнең үз-үзләрен тотуларын җайга салырга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

566. Социаль конфликтларны хәл итү турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?
А. Иҗтимагый конфликтлы очраклар төрле типтагы җәмгыятьтә була.
Б. Крестьяннарның баш күтәрүе социаль конфликтның бер формасы булып тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

567. Гаилә турындагы түбәндәге фикерләр дөресме?

А. Гаилә базар икътисадының иң әһәмиятле институты булып тора.

Б. Гаилә баланың шәхесен формалаштыруда әһәмиятле роль уйный.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

568. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?

А. Барлык социаль нормалар кече төркемнәрдә барлыкка киләләр.

Б. Традицияләр һәм йолалар, гадәтләр бары язылу шартында гына социаль нормалар булып китә алалар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

569. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?

А. Социаль нормалар кешенең җәмгыятьтәге тәртибен җайга салуны үз өстенә ала.

Б. Барлык социаль нормалар дәүләт көче тарафыннан саклана.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

570. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А. Ике якның үз карашларын саклап калырга омтылу - социаль конфликтларның бер сәбәбе булып тора.

Б. Җәмгыять өчен социаль конфликтларның һәм уңай, һәм тискәре нәтиҗәләре булырга мөмкин.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

571. Һәрбер кешегә тормышта бик күп төрле социаль рольләр башкарырга туры килә. Яшүсм һәм олыларга хас булган социаль рольләр җыелмасын чагыштырып карагыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

**1)** метро пассажиры булу

**2)** кораллы көчләрдә хезмәт итү

**3)** кибеттә продуктлар сатып алу

**4)** җирле үзидарә органнарына сайлауларда катнашу

572. Бирелгән исемлектә зур һәм кече социаль төркемнәрнең охшаш һәм аермалы яклары китерелгән. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче багана аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

| | |
|---|---|
| **1)** | социаль структурада билгеле бер урын тоту |
| **2)** | шәхси контактларның мәҗбүри булмавы |
| **3)** | берләштерүче билгенең булуы |
| **4)** | төркемдәге барлык әгъзаларның турыдан-туры хезмәттәшлеге булмау |

573. Җәмгыять белеме укытучысы дәрестә социаль нормалар турында аңлата. Әхлак һәм хокукый нормаларны чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

**1)** үз-үзеңне тиешле тоту турындагы җәмгыятьнең күзаллауларын чагылдыралар

**2)** компетентлы дәүләт органнары тарафыннан булдырылалар

**3)** күпчелек очракта сөйләмә формада булалар

**4)** кешеләрнең үз-үзләрен тотуларын җайга салалар

574. Социаль рольләр һәм социаль төркемнәр арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килгән элемент сайлап алыгыз.

| **СОЦИАЛЬ РОЛЬЛӘР** | | **СОЦИАЛЬ ТӨРКЕМНӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | сатып алучы | **1)** | яшүсмерләр |
| **Б)** | Интернет файдаланучысы | **2)** | олылар |
| **В)** | гимназия укучысы | **3)** | яшүсмерләр дә, олылар да |
| **Г)** | офицер | | |
| **Д)** | сайлаучы | | |

Таблицада сайлап алынган цифрларны тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

576. Гаиләэшчәнлегенең юнәлешләре һәм мисаллары арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килгән элемент сайлап алыгыз.

**МИСАЛЛАР** | **ГАИЛӘНЕҢ ЭШЧӘНЛЕК ЮНӘЛЕШЕ**

| | |
|---|---|
| **А)** ял көнендә гаилә белән урманга бару | **1)** хуҗалык эшчәнлеге |
| **Б)** өй мәшәкатьләрен ир һәм хатын арасында бүлешү | **2)** тәрбия эшчәнлеге |
| **В)** гаилә традицияләре белән танышу, аларны саклау һәм үстерү | **3)** ял вакытларын оештыру |
| **Г)** балаларны өстәл артында үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү | |
| **Д)** гаилә бюджетын планлаштыру | |

Таблицада сайлап алынган цифрларны тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

577. Социаль төркемнәр һәм җәмгыять структурасында бирелгән билгеләр арасында тәңгәлле урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килгән элемент сайлап алыгыз.

| **СОЦИАЛЬ ТӨРКЕМНӘР** | | **БИЛГЕЛӘР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | Рязань шәһәрендә яшәүчеләр | **1)** | профессиональ |
| **Б)** | табиблар | **2)** | территориаль |
| **В)** | авыл кешеләре | **3)** | сәяси |
| **Г)** | демократлар | | |
| **Д)** | агрономнар<br>Таблицада сайлап алынган цифрларны тиешле хәрефләр астына язып куегыз. | | |

578. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Бөтендөнья сәламәтлекне саклау оешмасы китергән мәгълүматлар буенча, алкоголизм ел саен 6 млн. кешенең гомерен алып китә. (Б) 40% акыл ягыннан зәгыйфь балаларның әти-әниләре – алкоголиклар. (В) Бу ситуациянең саклануы кешеләрнең киләчәгендә тискәре чагылыш табарга мөмкин дип уйлыйбыз.

Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә

579. Һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.
(А) Этникара конфликтларны булдырмау өчен, хөкүмәткә илдә социаль-икътисадый хәлне тотрыкландыру буенча чаралар кабул итү җитә. (Б) Z илендә этникара каршылыклар җирлегендә бәрелешләр булды. (В) Халык арасында социологик сораштырулар күрсәткәнчә, конфликтның төп сәбәбе күпчелек халыкның яшәү шартларының түбән булуы белән бәйле.
Текстның кайсы нигезләмәсе

1) фактларны чагылдыра

2) фикерләрне белдерә.
Тиешле нигезләмәләрнең характерын билгеләүче цифрларны таблицага язып куегыз.

580. Дәрестә укытучы кече төркемнәр турында сөйләде. Гаиләне һәм хезмәт коллективын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

1) мәнфәгатьләрнең уртак булуы

2) уртак йорт хуҗалыгын алып бару

3) туганлык бәйләнеше

4) шәхси элемтәләр

581. Дәрестә укытучы социаль нормалар турында сөйләде. Хокук һәм әхлак нормаларын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

1) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салалар

2) махсус актларда теркәләләр

3) дәүләт көче белән якла632лар

4) иҗтимагый үсешкә тотрыклылык өстиләр

582. Кайсы билге гаиләне башка төр кече төркемнәрдән аерып тора?

1) уртак эшчәнлек

2) гомуми максатлар

3) гомуми көнкүреш

4) үз-үзеңне тоту нормалары булу

583. Кайсы мисал заманча гаиләнең икътисадый функциясен күрсәтә?

**1)** Гаилә киңәшендә яңа автомобиль алу турында карар кабул ителде.

**2)** Ял көнендә әтисе улы белән шәһәр паркына юнәлделәр.

**3)** Әбисе оныгына математикадан һәм рус теленнән өй эшен хәзерләргә булыша.

**4)** Әтисе кечкенә улына кунакта үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлатты.

584. Этник төркемнәр турындагы фикерләр дөресме?

А. Этник төркемнәрне уртак тел һәм мәдәният берләштерә.

Б. Этник төркемнәр бер профессия кешеләрен берләштерә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

585. Милләтара мөнәсәбәтләр турындагы фикерләр дөресме?

А. Уңышлы милләтара хезмәттәшлек шартларына этник азчылыкка хөрмәт күрсәтүне кертәләр.

Б. Хәзерге дөньяда милләтара конфликтлар территориаль бәхәсләр аркасында туарга мөмкин

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

586. Социаль конфликт турындагы фикерләр дөресме?

А. Социаль конфликтта катнашучылар төркем һәм бердәмлек саны буенча шактый булырга мөмкин.

Б. Теләсә кайсы социаль конфликт җәмгыятьне җимерү нәтиҗәләренә китерә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

587. Иванга 15 яшь. Аның гаиләсе – әти-әнисе һәм олы обыйсы. Түбәндәге сыйфатламаларда нәрсә чагыла?

1) социаль мобильлек
2) шəхси абруй
3) шəхеснең социаль статусы
4) кешенең билгеле бер этник төркемгə каравы

588. Түбəндə китерелгəн терминнарның кайсысы җəмгыятьнең демографик структурасын характерлый?

1) хатын-кызлар, ир-атлар
2) ата-аналар, балалар
3) белоруслар, татарлар
4) мөселманнар, христианнар

589. Əхлак нормага мисал булган очракны күрсəтегез.

1) Ашар алдыннан кулларны юарга кирəк.
2) Җəмəгать транспортында билетсыз йөрү штраф белəн хөкем ителə.
3) Өй туенда фатирга беренче булып мəче керергə тиеш.
4) Үз вəгъдəлəреңне үтəргə кирəк.

590. Кайсы социаль рольне яшүсмерлəр дə, олы кешелəр дə башкара ала?

1) мəктəп укучысы
2) пациент
3) опекун
4) попечитель

591. Җəмгыятьнең структурасы социаль бердəмлеклəр һəм төркемнəр, аларның элемтəлəренең күптөрлелеге белəн тəкъдим ителə. Кайсы социаль төркем профессиональ билге буенча аерыла?

1) пассажирлар

2) ир-атлар
3) шәһәр кешеләре
4) инженерлар

592. “Бала үзенең өендә күргәнне өйрәнә: ата-ана – аңа үрнәк”, - дип язган борынгы алман теле гуманисты. Бу шигъри юллар гаиләнең кеше тормышындагы нинди роле турында сөйли?

1) уртак ял вакытларын оештыру
2) туганлык бәйләнешләрен ныгыту
3) уртак йорт хуҗалыгын алып бару
4) балаларны тәрбияләү

593. Кайсы терминнар «социаль нормалар» төшенчәсенә туры килә?

1) кисәтү, рөхсәт итү
2) уку, белем
3) фикерләү
4) класс, катлам

594. Социаль нормаларны җайга сала торган хәрәкәтләр һәм төрләр арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килгән элемент сайлап алыгыз.

| ХӘРӘКӘТЛӘР | СОЦИАЛЬ НОРМА ТӨРЛӘРЕ |
|---|---|
| А) васыятьнамә төзү | 1) хокукый нормалар |
| Б) дуска ярдәм итүдән баш тарту | 2) әхлак нормалар |
| В) банктан ссуда алу | |
| Г) автобуста утырып барганга түләү өчен баш тарту | |
| Д) мәктәп укучыларының йорт вазифаларын үтәүләре | |

Таблицада сайлап алынган цифрларны тиешле хәрефләр

астына  язып куегыз.

595. Кайсы социаль рольне бала да, олы кеше дә башкарырга сәләтле?

**1)** опекун

**2)** шофер

**3)** сайлаучы

4) варис

596. Милләтара конфликтлар турындагы  фикерләр дөресме?

А. Милләтара  конфликтлар көнкүреш дәрәҗәсендә туарга мөмкин.

Б. Россия законнары нигезендә милләтара ызгышны кабызып җибәрү  җаваплылыкка

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

597. Ксения әти-әнисе һәм апасы белән тора. Ул  5 нче сыйныфта укый.  Ике кече төркемне – гаиләне һәм мәктәп сыйныфын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

**1)** үз-үзеңне тотуның махсус нормалары булу

**2)** төркем әгъзаларының шәхси элемтәләре

**3)** туганлык мөнәсәбәте

**4)** уртак көнкүреш

598. Түбәндә китерелгән терминнарның кайсысы җәмгыятьнең демографик структурасын характерлый?

**1)** өлкән яшьтәге кешеләр, яшьләр

**2)** руслар, украиннар

**3)** маргиналлар, урта катламнар

**4)** Православие динен тотучылар, буддистлар

599. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А. Теге яисә бу мәсьәлә буенча тулы мәгълүматның булмавы социаль конфликтларның сәбәбе булырга мөмкин.

Б. Социаль конфликтлар каршы тору кискенлеге һәм катнашучыларның саны буенча аерыла.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

600. Этнослар турындагы фикерләр дөресме?

А. Кабиләләр, халыкчанлык, милләтләр – болар этнос төрләре.

Б. Теләсә кайсы этник бердәмлекнең әгъзаларын тел берлеге, инану, гомуми гражданлык берләштерә.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

601. Кайсы социаль факт гражданинның сәяси ролен күрсәтә?

**1)** Александр Николаевич үз илендә ясалган телевизор сатып ала.

**2)** Җиңел атлетчылар Олимпия уеннарында медаль яулап алалар.

**3)** Ирина Валерьевна мәктәптә 25 ел эшләгән.

**4)** Юрий Анатольевич сайлауларда тавыш биргән.

602. Гаилә функцияләренә нәрсә карый?

1) балаларны тәрбияләү
2) салым түләү
3) социаль нормаларны билгеләү
4) сәяси тотрыклылыкны урнаштыру

603. Петровлар гаиләсе ир белән хатын һәм аларның 3 яшьлек балаларыннан тора. Алар ирнең әти-әниләре һәм әбисе белән торалар. Петровлар гаиләсе кайсы типка карар?

1) нуклеар
2) авторитар
3) демократик
4) киңәйтелгән гаилә

604. Тува республикасының Кызыл шәһәренә килгән кешеләр, һичшиксез, Азиянең географик үзәгенә - Енисей елгасының ике чыганагы кушылган урынга - таш стелла янына барырга тиеш дип санала. Монда нинди күренеш чагыла?

1) этикет
2) традицияләр
3) хокук
4) әхлак

605. Улын иптәшенең туган көн бәйрәменә җибәрер алдыннан, әти-әниләре аңа кунакта үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләделәр. Бу мисал гаиләнең нинди функциюсен күрсәтеп тора?

1) эмоциональ
2) тәрбияви
3) ял итү
4) репродуктив

606. Николай әти-әнисе һәм абыйсы белән яши. Ул 7 нче сыйныфта укый. Ике кече төркемне – гаиләне һәм мәктәп сыйныфын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип санын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип саннарын сайлап язып куегыз.

1) туганлык мөнәсәбәте
2) төркем әгъзаларының шәхси элемтәләре
3) үз-үзеңне тотуның махсус нормалары булу
4) уртак көнкүреш

607. Социаль нормаларның характеристикалары һәм төрләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: беренче баганада бирелгән һәрбер элементка икенче баганадан туры килгән элемент сайлап алыгыз.

| **ХАРАКТЕРИСТИКАЛАР** | **СОЦИАЛЬ НОРМА ТӨРЛӘРЕ** |
|---|---|
| А) законнарда һәм законлы актларда теркәлә | 1) әхлак нормалар |
| Б) иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга сала | 2) хокукый нормалар |
| В) дәүләт көче белән саклана | 3) әхлак һәм хокукый нормалар |
| Г) барыннан да элек, иҗтимагый фикерне чагылдыра | |
| Д) яхшылык һәм начарлык позициясеннән чыгып бәяләнә | |

Сайлап алынган цифрларны таблицада тиешле хәрефләр астына язып куегыз.

608. Җәмгыятьнең эчке төзелешен тәэмин иткән, үзара элемтәләр урнаштырылган социаль төркемнәрнең җыелмасы нәрсә дип атала?

1) социаль институт
2) социаль мобильлек

**3)** социальной төзелеш (структура)

**4)** социаль тигезсезлек

609. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?

А. Барлык социаль нормалар дәүләт көче белән саклана.

Б. Социаль нормалар үзләренең характерларына карап, рөхсәт бирмәүче, рөхсәт бирүче һәм кисәтүче булырга мөмкин.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

610. Түбәндә саналып кителгән социаль төркемнәрнең кайсысы профессиональ билге ягыннан аерыла?

**1)** мәскәүлеләр

**2)** яшьләр

**3)** консерватор

**4)** хәрби хезмәткәрләр

611. Павел дустына химиядән контроль эшкә әзерлеккә ярдәм итәргә ышандырган, ләкин үз сүзен тотмаган. Бу ситуация кайсы нормалар белән җайга салына?

**1)** хокукый

**2)** әхлак

**3)** сәяси

**4)** эстетик

612. Кайсы терминнар «социаль нормалар» төшенчәсенә карый?

1) кисәтү, тыю

2) тәрбия, мәгариф

3) фикерләү, сөйләм

4) сайлау, референдум

613. Социаль нормалар турындагы фикерләр дөресме?
А. Социаль нормаларны үтәү фәкать иҗтимагый фикергә таянып тормышка ашырыла.
Б. Социаль нормалар җәмгыять тормышын җайга салалар.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

614. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А. Ике фирманың торак булмаган бинага милек хокукын даулау бәхәсен суд нигезендә тикшерү сәяси конфликтка мисал булып тора.

Б. Футбол буенча дөнья чемпионаты уздыру икътисадый конфликтка мисал булып тора.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

615. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А. Территориаль бәхәс социаль конфликтның сәбәбе булырга мөмкин.

Б. Оешма эшчеләре һәм аның администрациясе арасында хезмәт өчен түләүне яхшырту уңаеннан туган конфликт икътисадый конфликтка мисал булып тора.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

616. Социаль конфликтлар турындагы  фикерләр дөресме?

А. Ата-аналар һәм балалар арасындагы конфликт һәрвакыт сәяси төс ала.

Б. Теге яисә бу өлкә эшчеләренең баш күтәрүе социаль  конфликтка мисал булып тора.

1) А гына дөрес

2) Б гына дөрес

3) ике фикер дә дөрес

4) ике фикер дә дөрес түгел

617. Түбәндә саналып кителгән социаль төркемнәрнең кайсысы профессиональ билге ягыннан аерыла

1) абитуриентлар
2) экономистлар
3) шәһәр кешеләре
4) чыгарылыш сыйныф укучылары

618. Түбәндә саналып кителгән социаль төркемнәрнең кайсысы территориаль билге ягыннан аерыла?

1) дин әһелләре
2) европалылар
3) мөселманнар
4) хатын-кызлар

619. Түбәндә саналып кителгән социаль төркемнәрнең кайсысы территориаль билге ягыннан аерыла?

1) дин әһелләре
2) европалылар
3) мөселманнар
4) хатын-кызлар

620.«Традицияләр», «гадәтләр» терминнары, беренче чиратта, түбәндәге төшенчәне ачыклау өчен кулланыла

гражданлык җәмгыяте

дөньяви дәүләт

сәяси режим

социаль нормалар

621. Гаилә дә, хезмәт коллективы да түбәндәге төр була ала.

1) территориаль гомумилек
2) кече төркемнәр
3) социаль катламнар
4) формаль булмаган төркемнәр

622. Башка кече төркемнәрдән аермалы буларак, гаилә түбәндәге пункт белән характерлана

1) шәхси элемтәләр булу
2) партнёрлык мөнәсәбәтләре булу
3) уртак кызыксынулар
4) уртак хуҗалык алып бару

623. М. гаиләсендә биш яшьлек бала бар. Баланы мәктәпкә әби әзерли. Бу мисал гаиләнең кайсы функциясен күрсәтеп тора?

1) тәрбияви
2) репродуктив
3) хуҗалык
4) ял вакытларын оештыру

624. Парламент депутатларының социаль бердәмлегенә караган кешеләрнең берләшүе нигезендә кайсы билге ята?

1) сәяси
2) этник
3) территориаль
4) мәдәни

625. Түбәндәге социаль бердәмлекне территориаль билге буенча аерып чыгаралар

1) шәһәр кешеләре
2) крестьяннар
3) мөселманнар
4) либераллар

626. Кабиләләр, халыкчанлыклар, милләтләр —

1) этник бердәмлекләр
2) дәүләтнең үсеш этаплары
3) демографик төркемнәр
4) сәяси система формалары

627. Халыкчанлык та, милләт тә

1) үзләренең аерым мәдәни традицияләренә ия
2) дәүләтчелек билгеләренә ия
3) уртак хуҗалык системасы нигезендә берләшәләр
4) мәстәкыйльлеккә ия

628. Милләтара конфликтлар турындагы фикеләр дөресме?

А. Кабиләара сугышлар милләтара конфликтларның бер формасы булып торалар.

Б. Территориаль бәхәсләр милләтара конфликтларның бер сәбәбе булып торалар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

629. Социаль конфликтлар турындагы фикерләр дөресме?

А. Автобус пассажирларының бәхәсе социаль конфликтка китерә.

Б. Предприятие хуҗаларының, эшчеләрнең баш күтәрүенә җавап йөзеннән, предприятиеләрне ябуы шәхесара конфликтны чагылдыра.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

630. Калмыкия, Бурятия, Тываның күпчелек өлеше үзләрен буддистлар дип саныйлар. Бу билге әлеге регионда яшәүчеләрне түбәндәге бердәмлеккә караулары белән характерлана

**1)** демографик
**2)** профессиональ
**3)** территориаль
**4)** дини

631. Этник төркемнәр турындагы фикеләр дөресме?

А. Этник төркемнәргә мәдәни үзенчәлелек хас.

Б. Теләсә кайсы этник төркем үз дәүләтчелеген булдыруга омтыла.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

632. Этносоциаль билге буенча берләшкән төркемне күрсәтегез.

1) пассажирлар

2) либераллар

3) инженерлар

4) шәһәрдә яшәүчеләр

633. Социаль төркемнәр турындагы фикеләр дөресме?

А. Кешеләрнең социаль төркемгә берләшүләренең нигезе булып социаль әһәмиятле билге санала.

Б. Социаль төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләр рәсми документлар нигезендә җайга салыналар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

634. Башка кече төркемнәрдән аермалы буларак, гаилә түбәндәге белән характерлана

1) югары сәяси активлык

2) көнкүреш бердәмлеге

3) уртак кызыксынулар

4) социаль структура

635. Башка кече төркемнәрдән аермалы буларак, гаилә түбәндәге белән характерлана

1) көнкүреш бердәмлеге

2) махсус төркем кыйммәтләре

3) уртак кызыксынулар

4) төгәл структура

636. Башка кече төркемнәрдән аермалы буларак, гаилә түбәндәге белән характерлана

1) көнкүреш бердәмлеге

2) үзара ярдәм (ярдәмләшү)

**3)** традицияләр булу

**4)** үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен эшләп чыгару

637. Гаилә ул –

**1)** җитештерү факторы

**2)** этник бердәмлек

**3)** сәясәт системасы элементы

**4)** кече социаль төркем

638. Гаилә һәм гаиләдәге мөнәсәбәтләр турындагы фикерләр дөресме?

А. Гаилә әгъзалары үзара әхлак һәм хокук җаваплылыгы белән бәйләнгән.

Б. Гаилә кешенең төрле ихтыяҗын канәгатьләндерү чыганагы булып тора.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

639. Диңгезгә беренче тапкыр килгән һәр кеше, бирегә яңадан әйләнеп кайту өчен, диңгезгә тәңкә ыргытырга тиеш дип санала. Бу мисал кайсы нормалар эшчәнлеген күрсәтә?

**1)** этикет

**2)** әхлак

**3)** традицияләр

**4)** хокук

640. Һәрбер кешегә тормышта күп төрле социаль рольләр башкарырга туры килә. Унике яшьлек яшүсмернең һәм олы кешенең социаль эшчәнлек җыелмасын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип саннарын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

1) социаль байлыклардан файдалану

2) шартнамәләр һәм килешүләрне дәүләт дәрәҗәсендә теркәү
3) белем алу мөмкинлеге
4) үзеңнең милкең һәм хезмәтең белән файдалану

---

641. Җәмгыять белеме дәресендә укытучы халыкчанлык һәм милләт төшенчәләрен характерлады. Бу ике этник бердәмлекне чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип саннарын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.
1) территориясе ягыннан яшәү урынының бер булуы
2) тотрыклы икьтисадый бәйләнешләр белән бәйләнгән
3) уртак мәдәни традицияләре булу
4) дәүләтчелек формалашу шартларында барлыкка килә

642. Кайсы социаль роль яшүсмергә дә, олы кешегә дә хас?

**1)** гаилә әгъзасы

**2)** фирма директоры

**3)** опекун

**4)** төп мәктәп укучысы

643. Кайсы социаль рольне яшүсмерләр дә, олы кешеләр дә башкара ала?

**1)** кулланучы

**2)** сайлаучы

**3)** урта мәктәп укучысы

**4)** машина йөртүче

644. Сергей әти-әнисе һәм әбисе белән яши. Ул 8 нче сыйныфта укый. Бирем шартында телгә алынган ике кече төркемне – гаиләне һәм мәктәп сыйныфын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип саннарын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

---

**1)** уртак көнкүреш

**2)** туганлык мөнәсәбәтләре

**3)** туганлык мөнәсәбәтләре

**4)** махсус үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булу

645. Сергей әти-әнисе һәм әбисе белән яши. Ул 8 нче сыйныфта укый. Бирем шартында телгә алынган ике кече төркемне – гаиләне һәм мәктәп сыйныфын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип саннарын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

1) төркем әгъзаларының шәхси элемтәләре
2) уртак көнкүреш
3) туганлык мөнәсәбәтләре
4) үзенчәлекле үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булу

646. Антон әнисе һәм бабасы белән яши. Ул 7 нче сыйныфта укый. Ике кече төркемне – гаиләне һәм мәктәп сыйныфын чагыштырыгыз. Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның тәртип саннарын, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлап язып куегыз.

1) төркем әгъзаларының шәхси элемтәләре
2) уртак көнкүреш
3) туганлык мөнәсәбәтләре
4) үзенчәлекле үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булу

647. Түбәндәге һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү – сәламәт яшәү рәвеше алып баруның мөһим элементы булып тора. (Б) Иҗтимагый фикерне сорау фонды мәктәптә физкультура дәресләренең кирәклеген белү өчен россиялеләрдән сорау үткәрде. (В) Сораудa катнашкан гражданнарның 65% ы, мәктәптә физкультура дәресләре бөтен кеше өчен мәҗбүри булырга һәм атнасына 2-3 тапкырдан да ким булмаска тиеш дип саныйлар.

Текстның кайсы нигезләмәләре

**1)** фактларны чагылдыра

**2)** фикерләрне белдерә

649. Түбәндәге һәрбер нигезләмәсе хәреф белән билгеләнгән текстны укып чыгыгыз.

(А) Социологик сорау алу мәгълүматларына караганда, хатын-кызлар 18-20 яшьтә эшли башларга, 21-24 яшьтә кияүгә чыгарга, шулай ук әти-әнидән аерым яшәргә һәм чагыштырмача шул яшьтә бала табарга планлаштыралар. (Б) Ир-атларның тормышларының нинди булуы турындагы күзаллаулары берникадәр аерыла: алар иртәрәк эшли башларга, ә инде өйләнергә һәм балалар тудырырга соңрак – 25-28 яшьтә генә уйлыйлар. (В) Егетләргә караганда кызларның әти-әни куышыннан иртәрәк чыгып китәргә

телəүлəрен билгелəп үтəргə кирəк.
Текстның кайсы нигезлəмəлəре

1) фактларны чагылдыра
2) фикерлəрне белдерə

650. Түбəндəге һəрбер нигезлəмəсе хəреф белəн билгелəнгəн текстны укып чыгыгыз.

(А) Социологлар балигъ булган гражданнарга, нинди гаилəне идеаль дип атап була дигəн сорау бирəлəр. (Б) Сорау алуда катнашканнарның күбесе идеаль гаилə образын мəхəббəт, ихтирам һəм үзара җаваплылык белəн бəйлəп карыйлар. (В) Иң мөһиме – бу идеалның матур сүзлəр булып кына калмыйча, көндəлек тормышта реальлəшкəн булуы.

Текстның кайсы нигезлəмəлəре

1) фактларны чагылдыра
2) фикерлəрне белдерə

651. Түбəндəге һəрбер нигезлəмəсе хəреф белəн билгелəнгəн текстны укып чыгыгыз.

А) Хəзерге җəмгыятьтə үзенең махсус мəдəнияте, үз-үзеңне тоту нормалары булган күп сандагы социаль төркемнəр бар. (Б) Мондый күптөрлелекне хупларга мөмкин, чөнки ул кешелəрнең ихтыяҗын тулысынча канəгатьлəндерергə сəлəтле. (В) Лəкин нормаларның төрлелеге, мөгаен, кешелəрнең ориентларын бозарга, дөрес булмаган тəртип стимуллаштырырга мөмкин.

Текстның кайсы нигезлəмəлəре

1) фактларны чагылдыра
2) фикерлəрне белдерə

652. «Социаль нормалар» төшенчəлəре өчен түбəндəге терминнар кулланыла.

1) индивид, шəхес
2) традициялəр, йолалар, гадəтлəр
3) сəнгать, фəлсəфə

4) прокуратура, адвокатура

653. Түбәндәгеләрнең кайсысы гаиләнең функциясенә карый?

1) балаларны тәрбияләү
2) әйләнә-тирәне саклау
3) ресурсларның чикләнгәнлек проблемасын хәл итү
4) сәяси тотрыклылыкны хуплау

654. Гаиләне башка социаль төркемнәрдән нәрсә аерып тора?

1) максатлар берлеге
2) уртак эшчәнлек
3) уртак көнкүреш
4) уртак мәнфәгатьләр

655. А. укытучы булып эшли. Дәресләрдән тыш, ул укучылар белән бәйрәмнәр, бәйгеләр, экскурсияләр, сәфәрләр оештыра. А. эшләрендә нәрсә чагыла?

1) социаль роль
2) социаль конфликт
3) социаль төзелеш
4) социаль мобильлек

656. Яшүсмернең һәм олы кешенең мөмкин булган уртак социаль ролен күрсәтегез.

1) сайлаучы
2) хәрби хезмәткәр
3) футбол җанатары
4) гаилә башлыгы

657. Түбәндә китерелгән мисалларның кайсысы кулланучының социаль ролен күрсәтеп тора?

1) Виталий гитарада уйный белә.

2) Виктор  бик әйбәт рәсем ясый.

3) Анна  итальян теле курсларында укый.

4) Игорь урам футболы командасында уйный.

658. Кайсы социаль рольне яшүсмерләр дә, шулай ук олы кешеләр дә башкара ала

1) урта мәктәп укучысы

2) автомобилист

3) сайлаучы

4) кулланучы

659. Санкт-Петербургка килгән һәрбер кеше Фонтанка яры буенда булырга һәм Чижик-Пыжикның скульптурасына кагылып алырга тиеш дип санала. Бу мисал нәрсәне күрсәтә?

Ирле- хатынлы Семёновлар һәрбер якшәмбе үзләренең балалары белән музейларга яки театрларга йөриләр. Бу мисал гаиләнең кайсы функциясен күрсәтеп тора?

1) беренчел социаль контроль

2) хуҗалык

3) ял вакытларын оештыру

4) репродуктив

660. Һәр якшәмбе саен Николай һәм Анна үзләренең балалары белән берлектә музейларга һәм  театрларга йөриләр. Бу мисал гаиләнең кайсы ролен күрсәтеп тора?

1) беренчел социаль контроль

2) йорт хуҗалыгын алып бару

3) ял вакытларын оештыру

4) нәселне дәвам итү

661. Санкт-Петербургка килгән һәрбер кеше Фонтанка яры буенда булырга һәм Чижик-Пыжикның скульптурасына кагылып алырга тиеш дип санала. Бу мисал нәрсәне күрсәтә?

1) этикет

2) әхлак

3) традицияләр

4) хокук

662. Яңа өйләнешкән яшь парлар күпер рәшәткәсенә йозак элеп куйсалар, аларның никахлары бәхетле булачак дип санала. Күп шәһәрләрдә туй көннәрендә яшь парлар килә торган мондый махсус урыннар бар. Бу мисал нәрсәне күрсәтә?

1) этикет

2) әхлак

3) традицияләр

4) хокук

663. Төрле җәмгыятьтә дини нормалар

1) барлык халыкка да тарала

2) дәүләт мәҗбүр итүе белән тәэмин ителә

3) шәхес һәм хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала

4) дин тотучыларның әхлак аңнары белән яклана

664. “Изге эш эшли алу мөмкинлегең булса, аны иртәгегә калдырма, бүген эшлә” кагыйдәсе нәрсәгә мисал булып тора?

1) дини нормаларга

2) социаль санкцияләргә

3) этикет кагыйдәләренә

4) әхлак нормаларына

665. “Кеше сөйләгәндә бүлдермә” кагыйдәсе нәрсәгә мисал булып тора?

1) традицияләргә
2) әхлак нормаларга
3) хокук нормаларына
4) этикет кагыйдәләренә


666. Баланың беренче теше чыккач, көмеш кашык бүләк итү – нәрсәгә ияру мисалы булып тора?

1) дини нормаларга
2) хокук нормаларына
3) традицияләргә
4) эстетик нормаларга

667. Сигезенче сыйныф укучысы Николай әти-нисе, әбисе һәм ике сеңлесе белән яши. Мәктәп сыйныфы кебек кече төркемнән гаиләне нәрсә аерып тора?

1) турыдын-туры шәхси контактлар
2) уртак хуҗалык алып бару
3) үзенә бер төрле үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булу
4) мәнфәгатьләр берлеге

668. Галимнәр Z иле гражданнарыннан сорау алалар. Аларга: «Кеше тормышында гаилә нинди роль уйный?» - дигән сорау бирелә.
Сорау алуның нәтиҗәләре (сораувда катнашучыларның % бәйләнешендә) диаграмма рәвешендә тәкъдим ителгән.




Диаграммада чагылыш тапкан сорау алуның нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында язылып чыга һәм аларга аңлатмалар бирелә. Түбәндә китерелгән нәтиҗәләрнең кайсылары сорау алу барышында туган мәгълүматлардан килеп чыга?

Алар астында күрсәтелгән цифрларны яып куегыз.

**1)** Z илендә партнёрлык тибындагы гаиләләр өстенлек итә.

**2)** Кешеләр гаиләнең кеше тормышында мөһим роль уйнаганын аңлыйлар.

**3)** Сорауда катнашканнарның күпчелеге шәхси тормышта бәхетсез.

**4)** Z илендә күпбалалы гаиләләр шактый.

**5)** Кешеләр төрле тормыш ситуацияләрендә гаиләгә таяналар.

669. Китерелгән исемлектә диаграмма нигезендә ясап булган нәтиҗәләрне табыгыз һәм алар астында күрсәтелгән цифрларны яып куегыз.

**1)** Сорау алуда катнашканнарның өчтән бер өлеше хәзерге җәмгыятьтә гаиләнең кыйммәтен инкарь итәләр.

**2)** Сорау алуда катнашканнарның күпчелеге кеше тормышында гаиләнең ролен югары бәялиләр.

**3)** Сорау алуда катнашканнарның тигез өлеше хәзерге җәмгыятьтә гаиләнең кыйммәте кимеде һәм гаилә карьера үстерү өчен комаучау итә дип саныйлар.

**4)** Хәзерге җәмгыятьтә гаиләнең кыйммәте кимегән дигән фикер, гаилә күп төрле мәсьәләдә ярдәм итә дигән фикергә караганда популяррак.

**5)** Сорау алуда катнашканнарның дүрттән бере гаилә, беренче чиратта, материаль ярдәм бирә дигән фикердә торалар.

670. 2012 нче елда Z шәһәрендә дүртъелга исәпләнгән яшүсмерләрнең үз-үзләрен хокукка каршы тоту профилактикасы программасын гамәлгә ашыру башлана. 2015 нче елда хокук саклау органнары кабул ителгән чараларның нәтиҗәлелеген өйрәнделәр. Әлеге тикшеренүләр таблицада бирелгән.

| **Ел** | **2012** | **2013** | **2014** | **2015** |
|---|---|---|---|---|
| Яшүсмерләрнең хокук бозу саны | 5 000 | 5050 | 3 900 | 2 500 |

Китерелгән исемлектән таблица нигезендә ясап була торган нәтиҗәләр табыгыз һәм алар астында күрсәтелгән цифрларны язып куегыз.

**1)** 2014 нче ел белән чагыштырганда, 2015 нче елда яшүсмерләр арасында хокук бозу күрсәткече артты.

**2)** 2012 нче ел белән чагыштырганда, 2013 нче елда яшүсмерләр арасында хокук бозулар санының үсеше күзәтелде.

**3)** 2012 нче ел белән чагыштырганда, 2015 нче елга Z шәһәрендә яшүсмерләр арасында хокук бозулар саны ике тапкырга кимеде.

**4)** Z шәһәрендә яшәүче һәрбер унынчы яшүсмер 2013 нче елда хокук бозган.

**5)** 2012 -2015 нче еллар аралыгында, яшүсмерләр арасында хокук бозуның күпчелек өлеше 2013 нче елда теркәлгән.

671. Таблицада чагылыш тапкан сорау алуның нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында язылып чыга һәм аларга аңлатмалар бирелә. Түбәндә китерелгән нәтиҗәләрнең кайсылары сорау алу барышында туган мәгълүматлардан килеп чыга?

**1)** Z шәһәрендә яшүсмерләрнең тәртипләрен күзәтү буенча махсус комиссия төзелә.

**2)** Z шәһәрендә яшүсмерләрнең үз-үзләрен хокукка каршы тоту профилактикасы чаралары нәтиҗәле булып чыкты.


**3)** Шәһәр җитәкчелеге шактый күп сандагы яшүсмерләрне өстәмә белем бирү системасына кертеп җибәрә алды.

**4)** Z шәһәре яшүсмерләрнең җинаятьчелеген киметү эше буенча тәҗрибә белән уртаклаша ала.

**5)** 2020 нче елга яшүсмерләр мохитендә хокук бозулар туктатылачак.

672. Z шәһәрендә 17 яшьлек егет һәм кызлардан социаль һәм шәхесара конфликт вакытында үз-үзеңне тотуның иң нәтиҗәле ысулы турында сорау

алу булды.
Ике төркемне сораштыру нәтиҗәләре (җавап бирүчеләрдән % да) график формада бирелгән.




Китерелгән исемлектән диаграмма нигезендә ясап була торган нәтиҗәләр табыгыз һәм алар астында күрсәтелгән цифрларларны язып куегыз.

**1)** Сорау алуда катнашкан ике төркемдә дә ситуациядән китү ысулы иң популяр булып тора.

**2)** Егетләр өчен үз мәнфәгатьләрен яклау характерлы.

**3)** Сорау алуда катнашканнарның ике төркеменең дә дә өчтән бере ташламаларны сайлыйлар.

**4)** Кызларның күпчелек өлеше ситуациядән китүгә караганда, уртак тел табуны сайлыйлар.

**5)** Егетләр арасында, ташламага караганда, уртак тел табуга омтылуның популярлыгы кимрәк.

673. Диаграммада чагылыш тапкан сорау алуның нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында язылып чыга һәм аларга аңлатмалар бирелә. Түбәндә китерелгән нәтиҗәләрнең кайсылары сорау алу барышында туган мәгълүматлардан килеп чыга?

**1)** Егетләр белән чагыштырганда, кызлар агрессиягә күбрәк һәвәсрәк.

**2)** Сорау алуда катнашканнарныд күпчелек өлеше толеранлыкның нәрсә икәнен аңлыйлар.

**3)** Хәзерге заман яшьләре югары конфликтлы булулары белән аерылып торалар.

**4)** Конфликтны җайга салу ысулын сайлаганда җенес буенча аерылу

билгесе ягыннан аермалар күзәтелә.

5) Сорау алуда катнашучылар фикеренчә, конфликтларны җайга салганда, төрле стратегияләр кулланылырга мөмкин.

674. Урта сыйныф – үзенең статус позицияләре ягыннан югары һәм түбән сыйныфлар арасындагы урта бер урынны алып торучы җәмгыятьнең бер өлеше.

XX гасыр башында урта сыйныфларга вак милекчеләр һәм бәйсез эшмәкәрләрне кертеп караганнар. Ләкин алга киткән илләрдә “массакүләм байлык җәмгыяте”нең үсеше нигезендә, урта сыйныф вәкилләренең рәтләрен шактый тулыландырган ялланган хезмәтнең квалификацияле хезмәткәрләренең (менеджерлар, юристлар, бухгалтерлар һәм банк хезмәткәрләре, мәктәп һәм югары уку йортлары укытучылары, табиблар һәм башкалар) тормыш дәрәҗәләре күтәрелү барлыкка килә.

Галимнәр арасында урта сыйныфның критерияләрен билгеләүдә даими бәхәсләр бара. Еш кына белем һәм керем дәрәҗәсе, куллану стандартлары, матди яки интеллектуаль милек, шулай ук югары квалификацияле хезмәткә сәләтле булу төп объектив критерийлар булып саналалар. Әлеге объектив критерийлардан тыш, кешенең үз дәрәҗәсен субъектив тоюы, ягъни үзен “социаль урта” вәкиле итеп хис итүе дә зур роль уйный.

Төп социаль төркем буларак, алга киткән илләрнең урта сыйныфы бик мөһим булган социаль функцияләр башкара.

Алар арасында иң әһәмиятлесе - социаль стабилизатор функциясе: җәмгыятьнең социаль структурасында билгеле бер урынга ирешеп, урта сыйныф вәкилләре әлеге дәрәҗәләренә ия булырга мөмкинлек биргән, яшәп килгән дәүләт төзелешен яклыйлар. Социаль мобильлек процессларында урта сыйныфның әйдәп баручы роль үтәвен билгеләп үтәргә кирәк. Бу исә шулай ук яшәп килгән социаль стройны төрле социаль катаклизмнардан саклап ныгыта: түбән сыйныфның үз дәрәҗәсе белән канәгать булмау җәмгыятьтә үз статусларын күтәрергә реаль мөмкинлекләр күрүләре белән тигезләнә.

Икътисадый мөнәсәбәтләр өлкәсендә урта сыйныф икътисадый донор вазыйфасын үти – җәмгыять кеременең күп өлешен җитештерүче буларак кына түгел, ә эре кулланучы, инвестор һәм салым түләүче буларак та.

Мәдәни өлкәдә урта сыйныф җәмгыятьнең кыйммәтләре, нормалары, традицияләре һәм кануннарының саклаучысы һәм таратучысы булып тора.

Нәкъ менә урта сыйныф дәүләт аппаратын, бизнесны, төрле рангтагы түрәләр һәм идарәчеләрнең кадрлары белән тәэмин итә. Гражданлык җәмгыятенең эшчәнлеге шулай ук урта сыйныф вәкилләренең активлыкларына нигезләнгән.

*(Интернет-энциклопедия материалларыннан)*

675. Текст авторы тарафыннан урта сыйныфның нинди дүрт функциясе каралган? Җәмгыять тормышыннан алынган фактларны кулланып, урта сыйныф вәкилләренең социаль мобильлекләрен күрсәтегез.

676. Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып чыгарыгыз һәм аларның һәрберсенә исем кушыгыз. Автор гражданлык җәмгыятенең эшчәнлегендә урта сыйныфның әйдәп баручы ролен билгеләп уза. Урта сыйныфның әлеге активлык сәбәбенә ике фараз әйтегез.

677. Текстта галимнәр арасында урта сыйныфның критерияләрен билгеләүдә даими бәхәсләр бара дип әйтелгән. Бәхәс тудырырга мөмкин булган теләсә нинди ике сорау формалаштырыгыз.

678. Текстта урта сыйныфны билгеләүнең кайсы ике критериясе аталган?

679. «Социаль контроль» социологиядә гомумкабул ителгән төшенчәләрнең берсе булып тора. Аның белән теләсә кайсы җәмгыять үз әгъзаларының тәртибен бәяләү һәм төзәтү өчен куллана торган төрле чараларны билгелиләр. Бер генә җәмгыять тә социаль контрольдән башка булдыра алмый. Хәтта очраклы гына бергә җыелган зур булмаган кешеләр төркеменә дә, кыска арада таркалмау максатыннан, контрольнең махсус механизмын эшләп чыгарырга кирәк.

Хәзер, әйдәгез, һәрберсе билгеле бер социаль контрольне күрсәтеп торган берничә түгәрәкнең үзәгендә торган кешегә игътибарыбызны юнәлтик. Эчке түгәрәк белән бар кеше дә буйсынырга тиешле сәяси-юридик системаны билгеләп була. Бу - безнең теләгебезгә каршы салымнар җыярга, хәрби хезмәткә чакырырга, үзенең күп сандагы кагыйдәләренә һәм карарларына буйсынырга, ә инде кирәк булса, төрмәгә утыртырга сәләтле система.

Социаль контрольнең алдагы түгәрәге - үзәктәге ялгыз индивидка басым ясый торган әхлак, гореф-гадәтләр.

Индивид җәмгыятьнең башка әгъзалары белән бергә булган әлеге мәҗбүр итә торган зур түгәрәкләрдән тыш, контрольнең тагы да зуррак түгәрәкләре бар. Индивид тарафыннан сайлап алынган профессия үзендә котылгысыз рәвештә вакыты -вакыты белән хәтта шактый каты контрольлек йогынтысын йөртә. Индивидны рәсми рәвештә, әлбәттә инде, турыдан-туры җитәкчелек раслаган рәсми таләпләр контрольдә тоталар. Шулай ук коллегалар һәм хезмәткәрләр тарафыннан формаль булмаган төрле ысуллар да мөһимлеге ягыннан ким түгел. Җәмгыятьтәге теләсә кайсы профессиональ роле, хәтта иң мөһим булмаганы да, чынлыкта, санга сукмаска мөмкин булмаган, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренең махсус кодексын таләп итә.

Ниһаять, индивидның шәхси тормышы үтә торган кешеләр төркеме, ягъни гаилә һәм дуслар да, шулай ук контроль системасын барлыкка китерәләр. Бу түгәрәктәге басым, башка контроль системаларында булган мәҗбүр итүнең формаль чаралары булмаганга, калган түгәрәкләргә караганда көчсезрәк дип уйлау хата булыр иде. Нәкъ менә бу түгәрәктә индивид, кагыйдә буларак, иң мөһим социаль бәйләнешләргә ия.

*( П. Бергер буенча)*

Автор профессия ягыннан рәсми һәм формаль булмаган контрольне телгә ала. Кем һәм нинди максат белән аларның һәркайсын тормышка ашыра?

680. Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып чыгарыгыз һәм аларның һәрберсенә исем кушыгыз.

681. Дуслар Иванны юньсезлектә гаепләп, алга таба аның белән аралашудан баш тарттылар. Бу очракта нинди нормалар социаль контроль өчен нигез булдылар? Фикерегезне аңлатыгыз.

682. Теләсә кайсы җәмгыятькә социаль контроль зарур дигән фикергә үзегездән ике аргумент китерегез.

683. Автор «социаль контроль» төшенчәсенә нинди мәгънә сала? Социаль контрольнең нинди ике түгәрәге текстта аталып кителә?

684. Автор гаилә эчендәге контрольнең нинди үзенчәлеген китерә? Мондый контролньнең нәтиҗәлелеген ул ничек нигезли? Гаилә эчендә яки дуслар арасындагы социаль контрольгә ике мисал китерегез.

685. Бер телдә сөйләшә торган кешеләр, бер-берсен, төрле телдә сөйләшүчеләргә караганда, якынрак хис итәләр. Моның чагылышын без төрле җирдә күзәтә алабыз. Төрле телдәге кешеләр яши торган шәһәрләрдә, рус руска, немец немецка тартыла һәм башкалар. Чит илгә эләккән һәм аның телен белмәгән кеше үз телендә сөйләшүче кешене очратуына бик шат. Моны без бер дәүләт эчендә дә күрә алабыз.

Тел катламлавы, дәүләт һәм раса катламлавы белән чагыштырганда, бөтенләй башка сызык буенча баруын абайлавы бик җиңел. Бер дәүләтнең халкы, мәсәлән, Россиянең, бик күп төрле тел төркемнәреннән тора. Һәм, киресенчә, бер үк тел төркеме үзенең дәүләткә караганлыгы белән еш кына ике яки өч дәүләткә карарга мөмкин. Тел төркемләнүе раса бүленеше белән дә тәңгәл килмәскә мөмкин. Бер раса кешеләре, мәсәлән, ак кешеләр, төрле телләрдә сөйләшәләр, һәм, киресенчә, төрле раса кешеләре бер генә телгә ия булырга мөмкин.

Профессия термины астында кешенең яшәү чыганагы чарасы булып хезмәт иткән даими шөгылен аңларга кирәк. Табиб, инженер, игенче, фабрика эшчесе һ.б. шөгыльләре шундыйлардан. Хәзерге заман җәмгыятендә профессияләр бик күп төрле. Аларның саны берничә меңгә җитә. Профессиональ шөгыльләр кешенең бөтен рухи табигатендә, аның фикерләү рәвешендә, гадәтендә һәм зәвыгында үз эзен калдыра. Кешеләрнең профессияләрендәге охшашлык аларның кызыксынуларының, зәвыкларының, гадәтләренең охшашлыгына китерә; бер профессия кешеләрен бер-берсе белән теләктәш ясый. Хәзерге вакытта әгъзалары үзләренең уртак кызыксынуларын яклау максаты белән бер профессиональ төркемгә берләшмәгән профессияне табуы кыендыр.

Милек дәрәҗәсе һәм байлык буенча бүленеш, халыкны байларга һәм ярлыларга бүлү элек электән иң мөһим бүленеш булды.

*( П.А. Сорокин буенча)*

Җәмгыять белеме буенча алган белемегезгә таянып, иҗтимагый тормыштан алган фактлар нигезендә, авторның түбәндәге фикерләрен исбатлагыз:

а) «Бер дәүләтнең халкы, мәсәлән, Россиянең, бик күп төрле тел төркемнәреннән тора».

б) «бер раса кешеләре, мәсәлән, ак кешеләр, төрле телләрдә сөйләшәләр»;

в) «төрле раса кешеләре бер генә телгә ия булырга мөмкин.»

686.Кайсы социаль роль яшүсмерләр өчен дә, шулай ук олы кешеләр дә өчен дә характерлы?

| | | |
|---|---|---|
| | **1)** | гаилә әгъзасы |
| | **2)** | фирма директоры |
| | **3)** | опекун |
| | **4)** | төп мәктәп укучысы |

---

687. Түбәндә бирелгән кешенең үз-үзен тоту кагыйдәләренә караган парларның кайсылары әхлак нормаларына туры килә?

1) хокукка ярашлы – хокукка каршы (законсыз)
2) законлы булган– законлы булмаган
3) яхшы – усал
4) җәза бирелә торган – җәзасыз

688. Хәзерге җәмгыятьтә шәхес һәм хакимият органнары арасындагы мөнәсәбәтләрне нәрсә җайга сала?

| | |
|---|---|
| **1)** | дини нормалар |
| **2)** | сәяси нормалар |
| **3)** | корпоратив нормалар |
| **4)** | эстетик нормалар |

689.Эшчәнлек турында алдагы фикерләр дөресме?

А. Эшчәнлек – билгеле максатларга ирешү.

Б. Эшчәнлек билгеле максатка килүне күзаллый

1) бары тик А варианты дөрес

2) бары тик Б варианты дөрес

3) ике вариантта дөрес

4) ике вариантта дөрес түгел